Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяс авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

«18» ноябрь 2024 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 18 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Торнаяс поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр.инвалидлардан кала, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торнаяс торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

- Торнаяс торак пунктында ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерүмәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 170 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 91 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 91 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 10 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Торнаяс авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Торнаяс поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 гр.инвалидлардан кала, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, СВОда катнашучылардан кала, балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм әлеге кертемнәрне түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торнаяс торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

- Торнаяс торак пунктында ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авылы торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.Г. Еливанова

Заречный авыл җирлеге башлыгы Л.Г. Еливанова